ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2017 Казан ш. № 10-114/кс

«Казаньоргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте өчен техник суга (әйләнешле су белән тәэмин итү) һәм су бүлүгә (сәнәгый һәм явым-төшем агынты сулары) 2018-2020 елларга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шушы карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы «Казаньоргсинтез» гавами акционерлык җәмгыятенә техник суга (әйләнешле су белән тәэмин итү) һәм су бүлүгә (сәнәгый һәм явым-төшем агынты сулары) 2018-2020 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 нче пунктында билгеләнгән тарифлар 2018 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Шушы карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы «Казаньоргсинтез» гавами акционерлык җәмгыятенә техник суга (әйләнешле су белән тәэмин итү) һәм су бүлүгә (сәнәгый һәм явым-төшем агынты сулары) 2018-2020 елларга тарифларны җайга салуның дәвамлы параметрларын билгеләргә.

4. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы «Казаньоргсинтез» гавами акционерлык җәмгыятенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17

гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2017 № 10-114/кс карарына 1 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы «Казаньоргсинтез» гавами акционерлык җәмгыятенә техник суга (әйләнешле су белән тәэмин итү) һәм су бүлүгә (сәнәгый һәм явым-төшем агынты сулары) 2018-2020 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Техник суга тариф (әйләнешле су белән тәэмин итү) (бер ставкалы), сум/куб м. | | | | | | Су бүлүгә тариф (сәнәгый һәм явым-төшем агынты сулары) (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | |
| | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр |
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | | | | | | | | | | |
| 1 | «Казаньоргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелә) | 0,88 | 1,05 | 1,02 | 1,02 | 1,02 | 1,10 | 11,35 | 12,33 | 12,21 | 12,21 | 12,21 | 13,05 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2017 № 10-114/кс карарына 2 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы «Казаньоргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте өчен 2018-2020 елларга тарифларны җайга салуның дәвамлы параметрлары

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Казаньоргсинтез» халыкка ачык акционерлык җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | Техник су (әйләнешле су белән тәэмин итү) | 2018 | 66241,73 | 1 | - | - | 0,23 |
| | | 2019 | 68012,05 | 1 | - | - | 0,23 |
| | | 2020 | 69753,42 | 1 | - | - | 0,23 |
| 1.2 | Су бүлү (сәнәгый һәм явым-төшем агынты сулары) | 2018 | 20804,47 | 1 | - | - | 0,88 |
| | | 2019 | 21611,11 | 1 | - | - | 0,88 |
| | | 2020 | 22726,93 | 1 | - | - | 0,88 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге